## ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Арбузов Баран авыл торак пунктында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Арбузов Баран авыл торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының « Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Арбузов Баран авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 800 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

-авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау
-кыш һәм җәйге чорда юлларны карап тоту(чабу, кардан чистарту);
-тракторны карап тоту.
- төзекләндерү (штакетник һәм чыгым материаллары сатып алу);
- плотинаны төзекләндерү өчен материал сатып алу (буа өчен торба);
-бер урынлы бер контейнер мәйданчыгын ясау өчен материал сатып алу.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен , кабул ителгән көннән 10 көн эчендә Урман Асты Шонталасы авыл җирлегенең Арбузов Баран авыл торак пунктындагы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
Гражданнар җыенында рәислек итүче

Алексеевск муниципаль районы
Урман Асты Шонталасы авыл җирлеге башлыгы А.Ә.Җиһаншин